ЧАРШӘМБЕ
17 ФЕВРАЛЬ
1943 ел.
№ 39 (6761)
Аерым номеры 20 тиен.

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ ҺӘМ КАЗАН ШӘҺӘР КОМИТЕТЛАРЫ, ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ҺӘМ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ.

СОҢГЫ СӘГАТЬТӘ

БЕЗНЕҢ ГАСКӘРЛӘР ХАРЬКОВНЫ АЛДЫЛАР

16 нчы февральдә безнең гаскәрләр, соңыннан бик каты урам сугышларына күчеп киткән кискен штурмнан соң, ХАРЬКОВ шәһәрен алдылар.

ХАРЬКОВ өчен булган сугышларда безнең гаскәрләр немецларның «Адольф Гитлер» һәм «Райх» исемле ике танк дивизиясеннән һәм «Бөек Германия» исемле мотодивизиядән торган «СС» корпусын, шулай ук немецларның күп кенә пехота дивизияләрен һәм махсус частьларын тар-мар иттеләр.

ХАРЬКОВНЫ азат итү һәм бу районда дошманны тар-мар итү операциясе генерал-полковник иптәш Ф. И. ГОЛИКОВ командалыгындагы гаскәрләр группасы көчләре белән тормышка ашырылды.

ХАРЬКОВ өчен булган сугышларда генерал-лейтенант иптәш К. С. Москаленко, генерал-лейтенант иптәш П. С. РЫБАЛКО, генерал-лейтенант иптәш М. И. КАЗАКОВ һәм генерал-майор иптәш С. В. СОКОЛОВ берләшмәләре үзләрен аеруча күрсәттеләр.

ХАРЬКОВКА беренче булып генерал-майор иптәш Г. М. ЗАЙЦЕВ, полковник иптәш А. С. КОСТИЦЫН һәм генерал-майор иптәш С. С. МАРТИРОСЯН частьлары бәреп керде.

СОВЕТ ИНФОРМЮРОСЫ.

ТЕРЛЕКЧЕЛЕКНЕ ҮСТЕРҮ ӨЧЕН ӨЗЛЕКСЕЗ КӨРӘШЕРГӘ

Кызыл Армиябез фронтларда уңышлы һөҗүмнәр алып бара. Көн саен дистәләрчә авылларыбыз һәм шәһәрләребез немец оккупантлардан азат ителә.

Һөҗүм итеп барганда, армиянең тыл ярдәменә бигрәк тә мохтаҗ булуы, димәк; тылның фронт өчен берничә тапкыр арттырылган энергия белән эшләргә тиешлеге билгеле. Илебезнең хезмәт ияләре моны бик яхшы аңлыйлар. Бу барыннан да элек, аларның үз хезмәт постларында көннән-көн яхшырак эшләүләрендә, эш нормаларын бермә-бер арттырып үтәүләрендә, киләчәктә тагын да яхшырак эшләү өчен конкрет йөкләмәләр алып, җиң сызганып эшкә керешүләрендә күренә.

Безнең социалистик терлекчелек работникларында да бу патриотик сыйфат бик ачык чагыла. Без бүген «Кызыл Татарстан» газетасында Әтнә районының Киров исемендәге колхоз фермаларында эшләүчеләрнең мәкаләләрен урнаштырабыз. Аларның бөтенесенең дә омтылышлары бары бер теләккә, үз постларында мөмкин кадәр яхшырак эшләп, героик Кызыл Армиябезгә күбрәк һәм күбрәк булышлык күрсәтүгә юнәлдерелгән.

Ләкин югарыда әйтелгәннәр әле, безнең барлык колхозларыбызда да һәм совхозларыбызда да әнә шулай, әтнәлеләрчә эшлиләр дигән сүз түгел. Киресенчә, терлекчелекне үстерүгә һаман да әле әһәмият бирмәүчеләр генә түгел, бу гаять җитди бурыч өлкәсендә эшне үз агымына куючылар да бар. Менә Биектау районы колхозларыннан берничә факт. Бу районның Ленин исемендәге колхозында, колхоз председателе Барабанщиковның үз эшенә салкын каравы нәтиҗәсендә, күп кенә терлекләр һәлак булган. Терлек азыклары әрәм-шәрәм ителә. Урлау фактлары да бар. Барабанщиков бу фактларга бармак аша карап килә. Шул ук районның Марфин исемендәге колхозында да (председателе Макаров) соңгы 3 ай эчендә генә дә сату һәм һәлак булу аркасында дуңгыз фермасындагы 75 баштан бары 12 баш дуңгыз калган. Чистай районының Галактионов исемендәге совхозында терлекчелекнең торышы бигрәк тә аянычлы хәлдә. Бу турыда матбугатта бер тапкыр инде сигнал бирелүгә дә карамастан совхоз җитәкчеләре дә һәм шулай ук район җитәкчеләре совхоздагы кимчелекләрне бетерү буенча бик акрын кыймылдыйлар.

Кыш бик озын әле. Алда ачы буранлы суыкларның булмаячагына һичбер гарантия юк. Терлек абзарларының торышын тикшерергә, салкын керерлек барлык тишек-ярыкларны томаларга кирәк. Терлек азыкларын экономия белән тотуга, салам кебек тупас азыкларны алдынгы колхозлардагы кебек эшкәртеп ашатуга бигрәк тә зур әһәмият бирелергә тиеш. Гомумән, колхоз фермаларында терлек азыкларының экономия белән тотылуы буенча җаваплылык беренче чиратта колхоз председательләренә һәм ферма мөдирләренә йөкләтелгән. Алар бу эшне һәр көн күзәтеп барырга һәм терлек азыкларын әрәм-шәрәм итүчеләргә карата каты чаралар күрергә тиешләр.

Хәзер терлекләр масса күләмендә балалыйлар. Үрчемне тулысынча алырга һәм бер генә яшь терлекнең дә һәлак булмавына ирешергә кирәк.

Фермаларда эшләүче кадрларның күп кенә өлеше яшьләр, димәк, кайбер мәсьәләләрдә аларның тәҗрибәләре җитәрлек булмавын бер генә минутка да истән чыгармаска, моның белән беренче чиратта белгечләр-зоотехниклар һәм ветеринария работникларын кызыксындырырга, алар яшь кадрларга практик эштә конкрет булышлык һәм киңәш белән ярдәм итәргә тиешләр.

Терлекчелекне үстерү буенча өзлексез рәвештә көрәш барсын

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Председателенә

Хөрмәтле иптәш Динмөхәмәтов,

Татарстан республикасының хезмәт ияләре тарафыннан фронтка ярдәм күрсәтү турында Сезнең язма докладыгызны зур канәгатьләнү белән укып чыктым.

Заемга һәм акча-әйбер лотереясына язылуда, танклар колоннасы һәм авиаэскадрильялар төзелешенә средстволар туплауда Татарстан халыкларының актив катнашуы, Кызыл Армия сугышчыларына бик күп бүләкләр җибәрүләре—болар бөтенесе дә совет патриотизмының тирән күренешләре турында, тылның фронт белән өзелмәслек элемтәсе турында, Кызыл Армия турында халкыбызның кайгыртучанлык күрсәтүе турында сөйлиләр. Бу хәл немец оккупантларны тар-мар итү бурычларын үтәүгә безнең сугышчыларыбызны һәм командирларыбызны тагын да көчлерәк рухландыра.

Явыз дошманны җиңү өчен барлык совет халыклары белән берлектә тылда армый-талмый эшләүче Татарстанның эшчеләренә, колхозчыларына һәм интеллигенциясенә минем чын күңелдән сәламымны тапшырыгыз. Ватаныбызның азатлыгы һәм бәйсезлеге өчен батырлык белән сугышучы данлыклы татар сугышчыларына сәлам тапшырыгыз.

Промышленностьның эше һәм бигрәк тә авыл хуҗалыгы эшләренә әзерләк һәм аларны үткәрү буенча хөкүмәтнең барлык заданиеләре Сезнең республикагыз тарафыннан намус белән үтәлерләр, дип өмет итәм.

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе М. КАЛИНИН.

Москва, Кремль.
11 февраль, 1943 ел.

Совет Информбюросыннан

16 ачы ФЕВРАЛЬДӘГЕ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

16 нчы февральгә каршы төндә безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышлары алып бардылар.

* * *

Шахтыдан көнбатыштарак безнең гаскәрләр уңышлы рәвештә алга бардылар һәм халык яши торган 20 пунктны алдылар. Дошман ике арадагы чикләрдә тукталып калырга азапланды, ләкин совет частьлары гитлерчыларның планын өзәләр, аларны тар-мар итәләр һәм көнбатышка алып ташлыйлар. Халык яши торган бер пункт өчен барган сугышлар вакытында немецларның бер батальон мотопехотасы юк ителде. 30 автомашина, танкка каршы ата торган 11 орудие, күп санда пулеметлар һәм автоматлар кулга төшерелде.

* * *

Лихаядан көнбатыштарак безнең частьлар һөҗүм сугышлары алып бардылар һәм халык яши торган күп кенә пунктларны алдылар. Немецларның 44 танкысы, 233 йөк һәм 65 җиңел автомашиналары, 150 вагон, 21 паровоз, шартлау әйберләре склады, сугыш припаслары склады, элемтә частьлар склады һәм инженерлык милекләре склады кулга төшерелде.

* * *

Ворошиловскидан көньяк-көнбатыштарак Н-че часть 400 гә якын немец солдатларын һәм офицерларын кырып бетерде һәм 2 самоход орудие, 3 миномет, 13 пулемет кулга төшерде. Икенче бер участокта дошман безнең подразделениеләргә каршы зур группа мотопехота һәм берничә танк ташлады. Совет сугышчылары немецларны көчле ут белән каршы алдылар. Гитлерчылар сугыш кырында 3 ватык танкларын һәм 120 үле гәүдәләрен калдырып чигенделәр.

* * *

Чугуеводан төньяктарак безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып бардылар. Н-че часть сугышчылары дошманның оборона узелына бәреп керделәр, пленныйлар алдылар һәм трофейлар кулга төшерделәр. Икенче бер участокта безнең подразделениеләр, алга барган хәлдә, дошманның берничә контратакасын кире кайтардылар һәм 11 танк, 300 гә якын немец автоматчигын юк иттеләр.

* * *

Курск өлкәсе районнарының берсендә хәрәкәт итүче партизаннарның бер отряды соңгы вакытта аэродромнарда немецларның 14 самолетын юк иткән, дошманның 7 эшелонын юлдан чыгарган.

Карел-Фин ССР ның бер районында хәрәкәт итүче «За родину» исемле партизаннар отрядының бер группасы кötelмәгәндә дошман гарнизонына һөҗүм иткән, 35 солдат, офицерны кырып бетергән. Бер орудие һәм сугыш припаслары склады шартлатылган, прожектор установкасы җимерелгән. Партизаннарның икенче бер группасы 75 ак финны кырып бетергән, 3 казарманы яндырган һәм 2 самоход орудиене сафтан чыгарган.

* * *

Германиянең информбюросы болай дип белдерә: «Фронт линиясен кыскарту өчен планлы рәвештә хәрәкәт итү вакытында Краснодар шәһәре эвакуацияләнде». Гитлерчыларның бу мәгънәсез һәм акмак ялганнары упае белән немецларның үткән елның август аенда нәрсә язуларын искә алып китү бик урынлы булыр. Берлин радиосы 1942 нче елның 10 нчы августында шатлыгыннан тәкерек чәчә-чәчә бөтен дөньяга болай дип шапырынган иде: «Көньяк фронтта соңгы 24 сәгать эчендә сугышның нәтиҗәсенә хәлиткеч тәэсир ясый торган хәлләр булды. Советларга яңа җимергеч удар ясалды, моңа хәтта хәзер дә бәя биреп җиткерү мөмкин түгел. Германия гаскәрләре Краснодар һәм Моздок шәһәрләрен алдылар. Бу ике промышленность шәһәрен югалту гомуми хәрби хәлгә зур тәэсир ясаячак».

Шулай итеп, моннан ярты ел элек гитлерчылар «Краснодарны алу сугышның нәтиҗәсенә хәлиткеч йогынты ясый» диг исбат иткәннәр иде. Аларның әйтүе буенча, шул кадәр зур хәрби әһәмияткә ия булган шәһәрне фронт линиясен кыскарту өчен, үз теләкләре белән эвакуацияләделәр дип бүген аларга кем ышансын. Шулай ук немецларның күптән түгел генә, Германия Майкопта нефть чыгара инде, дип мактануларын да искә алып китү урынлы булыр. Немец газеталары һәм радиосы Берлинда «Кавказ тәмәкесен эшкәртү җәмгыяте» һәм башка шундый бандитлык оешмалары төзелү турында мактанганнар иде. Гитлерчылар Кавказда һәм Кубаньда озакка һәм җитди рәвештә урнашырга исәп тотканнар иде. Ләкин ул аларча барып чыкмады.

16 нче ФЕВРАЛЬДӘГЕ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

16 нчы февральдә безнең гаскәрләр, соңыннан бик каты урам сугышларына күчкән кискен штурм нәтиҗәсендә, Харьков шәһәрен алдылар.

Ростов өлкәсендә безнең гаскәрләр район үзәкләре **Большекрепинскаяны, Чалтырьны,** халык яши торган зур пунктлардан **Генеральный мостны, Солтан-Салыны, Крымны, Недвеговканы, Синявканы** алдылар.

Фронтның башка участокларында безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә сугышлар алып бардылар.

* * *

15 нче февральдә безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында дошманның гаскәрләр һәм йөкләр төялгән 100 гә якын автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар, 20 кыр һәм зенит артиллериясе батареясының утын бастырдылар, 6 сугыш припаслары складын шартлаттылар.

* * *

Новошахтинскидан көнбатыштарак безнең гаскәрләр алга киттеләр һәм халык

(Дәвамы 4 нче биттә).

Фронтовикларның гүзәл җиңүләренә хезмәттә яңа күтәрелеш белән җавап бирик!

Патриотик күтәренкелек

Көньяк һәм Көньяк-Көнбатыш фронт гаскәрләре дошманның каты каршылык күрсәтүен җиңеп, Ростов-Донны, Ворошиловградны һәм Красный Сулинны алдылар. Бу шәһәрләр яңадан безнеке! Нинди шатлыклы хәбәр бу!

Совет Информбюросының белдерүе.— «Соңгы сәгатьтә» — безнең илебезнең барлык почмакларына яшен тизлеге белән таралды. Ул завод-фабрикаларда, колхоз-совхозларда гаять зур патриотик күтәрелеш тудырды.

Күп кенә предприятиеләрдә төнге смена вакытында ук митинглар булып үтте. Партоешма секретаре урынбасары иптәш Козлов булган Н-че заводта совет гаскәрләренең гүзәл җиңүләре турындагы белдерүне эшчеләр радиодан күмәкләп тыңладылар. Начальнигы иптәш Андреев булган цехта үткәрелгән митингта диспетчер Балденков болай диде:

—Фронтовикларның җиңүләренә җавап итеп без — тылда эшләүчеләр—элек алган йөкләмәбезне срогыннан алда үтәргә — производство программасын 22 нче февральгә тәгәлләргә тиешбез.

Январь аендагы күрсәткечләр буенча Бөтенсоюз социалистик ярышында җиңеп чыккан һәм Дәүләт Оборона Комитетының күчмә Кызыл Байрагын алган Н-че завод цехларында Ростовны һәм Ворошиловградны немец оккупантларыннан азат итүгә багышланган митинглар аеруча зур күтәренкелек белән үтте. Көньяк һәм Көньяк-Көнбатыш фронтлар гаскәрләренең уңышлары белән рухланган эшчеләр үзләренә яңа йөкләмәләр алдылар, сугышчан продукция эшләп чыгаруны тагын да арттыру өчен аяусыз көрәшергә сүз бирделәр.

Н-че заводның беренче участогы начальнигы орденлы мастер иптәш Дикусар митингта бөтен коллектив исеменнән чыгыш ясап,—Кызыл Армиянең 25 еллыгы көненә участок планын үтәп чыгачак,—дип белдерде. Икенче участок февраль программасын 105 процентка үтәргә, бракны ике тапкырга киметергә булды.

Митинглардан соң ук эшчеләр алган йөкләмәләрен эш белән беркетү өчен үзләренең станоклары һәм машиналары янына бастылар.

ХӘРӘКӘТТӘГЕ АРМИЯ. Совет патриоты колхозчы Ферапонт Головатый сатып алган самолет Н-че гвардия авиачастеның гвардия майоры очучы Б. Н. Ереминга тапшырылды. Иптәш Еремин берүзе дошманның 7 самолетын, группалап сугышканда 14 самолетын атып төшерде. Рәсемдә: очучы истребительләр часть митингысында Ферапонт Головатый исеменә кабул ителгән рәхмәт хатына кул куялар.

ТАСС фотохроникасы.

РОСТОВ—БЕЗНЕКЕ!

КӨНЬЯК ФРОНТ, 15 февраль. (ТАСС ның махсус хәбәрчесеннән). Кичә берничә көнгә сузылган бик каты сугышлар нәтиҗәсендә безнең гаскәрләр Ростов-Дон шәһәрен алдылар.

Ростовны алу белән Дон белән Волга арасындагы гаять киң мәйданда сугышлар тәгәлләнде.

Турыдан-туры Ростов өчен булган сугышлар Батайск районында башланып китте. Төнлә белән кинәт ясалган удар нәтиҗәсендә немецлар халык яши торган һәм шәһәрне саклап тора торган 12 пункттан бәреп чыгарылдылар. Дошман лагерендә каушау башланды. Батайскидагы тимер юлларга танклар, машиналар, сугыш припаслары һәм азык төялгән эшелоннар килеп тулды.

Батайскины алган сугышчылар алдында боз белән капланган Дон җәелеп ята иде. Инженерлык подразделениеләре, дошманның өзлексез уты һәм бомбага тотулары астында, елга аркылы кичүләрне көчәйтү эшен тәмам итеп киләләр иде. Безнең танклар шушы кичүләрдән үтәргә тиешләр иде.

Көн уртасына Яшел атаудан боз буйлап шәһәргә таба танклар китте. Тизлек һәм басым үзләренең нәтиҗәләрен бирделәр. Иртә белән совет сугышчылары шәһәрнең көньяк өлешен, вокзалны һәм завод районын алдылар.

Сугыш һаман көчәя барды. Гитлер генераллары Ростовны актык мөмкинлеккә кадәр саклап калырга приказ алганнар иде. Шунлыктан алар котырынып, каршылык күрсәттеләр. Дошман, яңадан танк һәм пехота частьлары китереп, бик күп контратакалар ясады. Ләкин алар барысы да тәмам җимерелү белән беттеләр. Сугыш кыры дошманның гаять күп үле гәүдәләре һәм җимерелгән техникасы белән капланды.

10 нчы февральдә Н-че берләшмә, киң фронтта немецларның оборонасын өзеп, башта, Шахтыга, ә аннан Новочеркасскига таба омтылды һәм бу шәһәрне төньяктан һәм көньяктан әйләнеп үтте. Озакламый немецлар Шахтыдан һәм Новочеркасскидан бәреп чыгарылдылар. Шуннан соң Ростов-Дон өчен булган сугыш хәлиткеч фазага керде. Безнең частьлар, Новочеркасскины алганнан соң кискенлек белән Ростовка каршы һөҗүмгә күчтеләр. Немецлар каршылык күрсәтүне көчәйттеләр. Алар, ишек алларыннан, йортлардан һәм чардаклардан торып, бер өзлексез пулеметлардан, автоматлардан аттылар. Урамнарда әледән-әле бик каты штык сугышлары булып торды. 14 нче февральдә безнең гаскәрләр, көньяктан, көнбатыштан һәм көнчыгыштан тупланган удар ясап, Ростов-Дон шәһәрен алдылар.

Бу штурмда генерал-лейтенант иптәш В. Ф. Герасименко гаскәрләре үзләрен аеруча күрсәттеләр. Шәһәргә беренче булып подполковник иптәш Ковалев, подполковник иптәш Сизанов, полковник иптәш Дряхлов, майор иптәш Дубровин частьлары бәреп керде. Шәһәрне алуга, көнбатыштан әйләнеп үтү юлы белән, полковник иптәш Шапкин һәм майор иптәш Ходос частьлары булышлык итте.

Ростов өчен сугыш совет гаскәрләренең бик яхшы җиңүе белән тәмам булды.

Н. МАРКОВСКИЙ.

БАРЫСЫ ДА ФРОНТ ӨЧЕН!

Бөек ватан сугышы фронтларында совет гаскәрләренең яңадан-яңа җиңүләргә ирешүләре Казан шәһәренең 1 нче тегү фабрикасы эшчеләре арасында хезмәт энтузиазмының яңа дулкынын күтәрде.

Ростов-Донның һәм Ворошиловградның Кызыл Армия тарафыннан алынуы уңае белән фабрикада митинг булып үтте. Митингта чыгыш сөйләүчеләрдән стахановчы иптәш Офицерова болай диде:

— Бөек ватан сугышы фронтларыннан көн саен шатлыклы хәбәрләр килеп тора. Безнең данлыклы Кызыл Армиябез изге җиребезне дошманнан тазарта. Кызыл Армиянең сугыш фронтларында җиңүләренә без, эшчеләр хезмәт фронтында яңа уңышларга ирешү белән җавап бирергә тиешбез.

Митингта катнашучылар Кызыл Армиянең 25 еллыгы хөрмәтенә производство программасын арттырып үтәргә, данлыклы Кызыл Армиягә тик яхшы сыйфатлы продукция бирергә йөкләмә алдылар.

Шатлык митингысы

АРЧА, 16 февраль. (Махсус хәбәрчебездән, телефон буенча). Совет Информбюросы тагын зур җиңү турында хәбәр китерде. Ростов шәһәре өстендә совет кызыл байрагы җилферди.

Шушы уңай белән «Кызыл яр» колхозы членнары үзләренең шатлыкларын уртаклашу өчен митингка җыелдылар. Биредә сүзләр кыска, конкрет булды.

Колхозчы иптәш Сафин:

— Кызыл Армиябезнең мондый зур җиңүенә эш белән җавап бирик. Чәчү орлыкларын чистартуны, агротехника чараларын үткәрүне, машиналарга һәм барлык сбруйларга ремонтны беренче мартка тәгәллик, дигән тәкъдим кертте.

Фронтовик иптәш Әһлиев:

— Без 1943 нче ел өчен Кызыл Армия фондына 128 центнер ашлык һәм 28 центнер ит тапшырдык инде. 1943 нче елгы дәүләт йөкләмәләренең дә 50 процентын беренче кварталда ук үти алабыз, диде. Митинг бу тәкъдимнәрне бер тавыштан кабул итте.

М. НУРЕТДИНОВА.

ГҮЗӘЛ ХӘРӘКӘТКӘ КИҢ КОЛАЧ!

Героик Кызыл Армиябез, фронтовикларның семьялары һәм балалары безнең барлык халкыбыз тарафыннан тирән кайгыртучанлык белән чолгап алынган.

Ватан сугышына киткән фронтовикларның семьялары, балалары турында кайгыртучанлык күрсәтү буенча безнең республикабызның комсомолецлары һәм пионерлары да байтак эшләр башкардылар. Комсомолецларның һәм союздан тыш яшьләрнең инициативасы белән 300.000 сумнан артык средство җыелды. ВЛКСМ өлкә комитеты бу средстводан 90 мең сумын фронтовикларның балаларын туклandыру өчен бирде. Мохтаҗ булган балаларга 12.000 пар эчке һәм тышкы киемнәр, аяк киемнәре алып бирелде.

Фронтовикларның семьяларына, балаларына ярдәм итүдә тимурчылар хәрәкәте зур урын тота. Казанның Свердлов районының 88 нче номерлы мәктәбендә укучы 11 пионер, Кызыл Армия сафына киткән иптәшләрнең семьяларына бардылар. Алар, аналары эштә вакытта аларның балаларын карап торуны оештырдылар, квартираларын чистарттылар.

Бу мәктәпнең башка укучылары да үзләренең районыннан фронтка киткән иптәшләрнең семьяларына йөреп чыктылар, аларның тормыш шартлары белән таныштылар һәм булышлык иттеләр. Бу яшь патриотлар, фронтовиклар балаларына 65 пар аяк киемнәре төзәтеп бирделәр. Бу эшкә өлкән вожатый иптәш Зальцман җитәкчелек итте.

Юдино районының 41 нче номерлы мәктәп пионерлары да өлкән вожатый иптәш Кирилова җитәкчелегендә, бу өлкәдә байтак эшләр эшләде. 6 нчы, 7 нче класс укучылары Борисов, Ларьянов һәм башкалар Кызыл Армия командиры семьясы иптәш Абрамовага зур булышлык күрсәттеләр. Бу турыда иптәш Абрамова пионер отрядына язган хатында болай ди:

— Мин фронтовик-командир хатыны. Минем 2 кечкенә балам бар. Үзем тимер юл транспортында эшлим. Пионерлар миңа зур ярдәм күрсәттеләр. Алар 3 кубометр утын ярдылар һәм башка эшләрдә булыштылар. Миңа һәм минем балаларыма игътибар белән караулары өчен пионерларга чын күңелдән рәхмәт әйтәм. Мин бу турыда үземнең иремә, фронтка да язачакмын, әлбәттә. Бу хәбәр аны дошманга каршы көрәшкә тагын да көчлерәк рухландырыр.

Чистай шәһәренең укучыларыннан оештырылган 18 бригада Кызыл Армия сафындагыларның семьяларына 75 кубометр утын кисеп бирделәр. Мондый фактларны күпләп китерергә мөмкин.

Комсомол, пионер оешмалары һәм мәктәп коллективы бу өлкәдә үзенең эшен тагын да киң җәелдерергә тиеш.

ВЛКСМ ның өлкә комитеты бюросы шушы елның 10 нчы февраленнән 1 нче мартына кадәр, фронттагыларның семьяларына ярдәм итү өчен ике ун көнлек игълан итте. Комсомолның шәһәр һәм район оешмалары бу ун көнлекләр турында киң аңлату алып барырга, барлык комсомолецларны, пионерларны һәм укучыларны бу эшкә оештырырга тиешләр. Барлык комсомол, пионер оешмалары бу ун көнлекләр эчендә нәрсә эшләргә тиешлекләре турында конкрет йөкләмәләр алырга һәм ул йөкләмәләрнең тәгәл үтәлешен тәэмин итәргә тиешләр.

Ленинград комсомолецларыннан үрнәк алып, ВЛКСМ ның район комитетлары һәм мәктәпләр янында комсомолецлардан һәм яшьләрдән, пионерлардан фронтовикларның семьяларына ярдәм итү командалары һәм ата-аналардан инициативный группалар оештырырга кирәк.

Ф. АБДУЛЛИН,

ВЛКСМ ның Татарстан өлкә комитеты секретаре.

КИРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ КОЛХОЗ ФЕРМАЛАРЫННАН ҮРНӘК АЛЫГЫЗ!

☆ ☆ ☆

ТӘҖРИБӘЛӘРНЕ УРТАКЛАШУ ӨЧЕН!

Колхоз строе авыл хуҗалыгының барлык тармакларын алга җибәрү өчен киң мөмкинлекләр тудырды. Илебездә бөртекле ашлык һәм техника культураларын гына түгел, терлекчелек продуктларын җитештерү дә киң колач алды.

Бу продуктларның күпчелек өлешен колхозларыбыз һәм совхозларыбыз бирәләр. Алар чын мәгънәсендә ашлык, ит, май, сөт, йон һәм башка бик күп төрле продуктлар эшләп чыгаручы фабрикаларга әйләнделәр.

Явыз дошманга каршы алып барыла торган хәзерге изге ватан сугышы социалистик терлекчелекнең фронтны һәм, гомумән, илебезнең әһәмиятле туклану әйберләре белән, промышленностебызны чимал белән тәэмин итүдә гаять зур урын тотканлыгын аеруча ачык күрсәтте. Бу, Әтнә районының Киров исемендәге колхоз фермалары эшендә генә дә ачык чагыла.

Бу колхоз фермалары сугыш башланганчыга кадәр дә начар эшләмиләр иде. Сугыш башлангач, күп кенә кыенлыклар булуга да карамастан, алар элеккегә караганда да яхшырак эшли башладылар. Яшь терлекнең үлүе, терлекчелекне үстерү буенча дәүләт планнарының үтәлмәве, дәүләткә терлекчелек продуктларын тапшыру планнарының үтәлмәве кебек кимчелекләр бу колхоз фермалары өчен ят нәрсәләр. Биредә тәртип. Биредә бай тәҗрибә. Биредә колхоз хуҗалыгын үстерү, терлекчелекне алга җибәрү өчен үз-үзеңне аямыйча эшләү.

Без түбәндә тәҗрибәләрне уртаклашу һәм терлекчелектә эшләүче яшь кадрларга киңәш тәртибендә, бу колхоз фермаларында эшләүче кайбер иптәшләрнең мәкаләләрен урнаштырабыз.

Безнең кайбер уңышларыбыз

Ватан сугышы барлык эшнең үзгәртеп, хәрби ладка корылуын таләп итте. Безнең социалистик терлекчелек тармагы алдына да, билгеле, шундый ук бурыч куелды. Чыннан да, Кызыл Армиябезнең дошманны тизрәк җиңүгә ирешүе без, терлекчелек работникларының да элеккегә караганда бермә-бер яхшырак эшләүләренә бәйләнгән.

Без моның шулай икәненә, сугыш башлангач та, сөекле юлбашчыбыз иптәш Сталин күрсәтмәләре буенча бик тиз төшендек һәм үзебезнең һәрбер эшебездә нәкъ әнә шуннан чыгып, ягъни фронт интересларын тулысынча канәгатьләндерү ягыннан чыгып эш итәргә тырыштык һәм хәзер дә тырышабыз.

Хезмәт бушка китмәде. Бу, безнең фермаларыбызның һәм бигрәк тә аерым стахановчыларыбызның эш нәтиҗәләрендә бик ачык чагыла. Менә берничә факт. 1942 нче елда, тавыклардан башка, барлык төр терлекләр буенча, дәүләт планын арттырып үтәдек. 1943 нче елның беренче январена фермаларыбыздагы мөгезле эре терлекләр саны 450 баш урынына 470 башка, сарыклар саны 435 баш урынына 480 башка, дуңгызлар саны 250 баш урынына 317 башка җитте.

1941 нче елда һәрбер фуражный сыердан план буенча билгеләнгән 14,0 центнер урынына 14,5 центнер сөт алдык. Сыерларның сөт бирүләрен арттыру буенча ныклы көрәш алып бару нәтиҗәсендә, үткән елны тагын да зуррак уңышларга ирештек: һәрбер сыердан план буенча 14,0 центнер урынына 14,8 центнер сөт савып алдык. Димәк, үткән елны безнең фермабыздагы һәрбер савым сыер планнан тыш 0,8 центнер сөт биргән булып чыга. Бу санны фермадагы барлык савым сыерлар санының уртача санына, әйтик 200 башка гына тапкырлаганда да без үткән елны планнан тыш 1.000 потка якын сөт алган булабыз. Бу, әлбәттә, кечкенә уңыш түгел.

Хәзер кыш көне. Ә кыш-терлекләрне саклап үстерүдә елның иң җаваплы чоры. Безнең колхоз шартларында бу бигрәк тә әһәмиятле.

Бу уңай белән түбәндәге гаять кызыклы бер фактны искә алмыйча китү һич тә мөмкин түгел. Гадәттә, октябрь, ноябрь һәм декабрь айларында сыерларның сөт бирүләре бик нык кими. Бездә дә ул шулай. Без үткән көз көне бу кимчелекне бетерү буенча махсус эш алып бардык һәм бик яхшы нәтиҗәгә ирештек. Мәсәлән, 1941 нче елның октябрь аенда һәрбер савым сыердан уртача бары 41 литр гына сөт алган булсак, 1942 нче елның шул ук аенда һәрбер сырдан уртача 86 литр сөт алдык. 1941 нче елның ноябрь аенда һәрбер савым сыердан уртача бары 16 литр сөт алган булсак, 1942 нче елның шул ук аенда 34 литр алдык. Декабрь аендагы аерма бигрәк тә зур: 1941 нче елда—9 литр, ә 1942 нче елда инде 23 литр. Кыска гына әйткәндә, без быел югарыда күрсәтелгән айларда сөт алуны үткән елдагыга чагыштырганда бермә-бер арттырдык.

Биредә тагын шуны әйтергә кирәк: 1941 нче елны октябрь, ноябрь һәм декабрь айларында һәрбер сыерга көн саен 0,5 килограмм исәбеннән концентрат азык бирдек, ә 1942 нче елда концентрат бөтенләй бирелмәде.

Октябрь, ноябрь һәм декабрь айларында сөт алынышында мондый зур аерма кайдан килеп чыкты соң? Барыннан да элек шуны әйтергә кирәк, без элекке елларда сыерларга силосны яз көне генә ашата башлый идек, ә үткән елны сыерлар көтүдән кайткач ук силос бирә башладык. Аннан соң фермада эшне һәр көнне төгәл билгеләнгән эчке тәртип кагыйдәләренә туры китереп оештырдык, терлекләргә карата ваемсызлыкны, хуҗасызлыкны тәмам бетердек.

Безнең фермабыз дәүләт алдындагы 1942 нче елгы барлык йөкләмәләрне тулысынча үтәде. Товарлыклы сөтчелек фермасы 1943 нче ел исәбенә дә 10 мең литрдан артык сөт тапшырды инде.

ФАТИМА КАМАЛИЕВА,

Әтнә районы, Киров исемендәге колхозның терлекчелек фермасы мөдире.

ЯШЬ ТЕРЛЕКЛӘРНЕ ТУЛЫСЫНЧА САКЛЫЙК!

Кыш—ул терлекчелектә җаваплы чор. Аның ничек үтүенә бәя биргәндә, барыннан да элек, яшь терлекнең тулысынча сакланып калуыннан чыгып эш ителә. Чөнки терлек санының артуы, димәк, дәүләт планының үтәлүе иң башлап әнә шуңар, яшь терлекнең сакланып калуына бәйләнгән.

Мин өченче ел инде бозаулар тәрбиялим. Шул вакыт эчендә колхозыбызга 86 бозау үстереп бирдем. Мин караган бозауларның берсе дә үлмәде.

Минем уңышларымның нигезе кайда соң? Әллә нәрсәдә түгел. Бары тик зоотехника һәм ветеринария кагыйдәләрен тулысынча тормышка ашыруда. Безнең бозауларның торагы чиста, якты һәм нормаль җылылыкта. Бозауларны дөрес ашатуга (бигрәк тә сөт эчү дәверендә) аеруча нык әһәмият бирәбез. Бозауларны туган көннән алып 10 көн буена тик үз әнкәләренең сөтләре белән генә туйдырабыз. Гомумән, бозау баштагы 70 көн эчендә 250—260 литр чамасы сөт эчәргә тиеш, һәм без моны бозауга тулысынча бирәбез. Туганнан соң 20 көн үткәч һәр бозауга 500 грамм исәбеннән солы оны яки арыш оны, шуннан соң 0,5 килограмм исәбеннән яхшы сыйфатлы печән бирә башлыйбыз. Бер айдан соң солы көрпәсеннән кесәл пешереп бирү бик файдалы.

Һәртөрле йогышлы авырулар бозауларга аеруча тиз йогучан. Шуңар күрә без бозаулар абзарына чит кешеләрне һич тә кертмибез. Кертсәндә дә халат кигезеп кенә кертәбез.

Безнең фермабызда сыерлар тиздән массовый төстә бозаулый башлыйлар. Мин бозауларны кабул итүгә һәр яктан әзер. Бина яхшы, азык җитәрлек.

ХӘТИМӘ КАМАЛИЕВА,

Әтнә районы, Киров исемендәге колхозның бозау караучысы.

Сарыкны күбрәк үрчетик

Сарык—бик файдалы терлекләрнең берсе. Ул безгә ит, брынза, май, йон, тире бирә. Ә бу продуктларның көнкүрештә тоткан урыннары һәрберебезгә билгеле. Фронтовикларыбызны җылы киемнәр белән тәэмин итүдә терлекчелекнең бу тармагы аеруча әһәмиятле. Менә шуңар күрә дә хәзер, явыз дошманга каршы кискен көрәш барган вакытта, сарык асырау эшенә җитди игътибар бирелергә тиеш.

Безнең сарык фермасы шактый зур. Тик соңгы ике ел эчендә генә дә без дәүләткә 50 баш сарык тапшырдык. Яңа фермалар оештыру өчен колхозларга 80 баш сарык саттык, тик 1942 нче елда гына да госпитальләрдә ятучы фронтовикларга 20 баштан артык сарык бүләк иттек. Дәүләткә берничә йөз сарык тиресе бирдек. Брынза өчен сөт тапшыруны үткән елны 200 процентка үтәдек.

Мин хәзерге көндә фермада сарык караучы булып эшлим. Миңа 60 сарык беркетелгән. Шулардан быел туган 64 бәрән бар.

Без бәрәннәрне ничек тәрбия итәбез соң? Алар ике айга кадәр аналары янында торалар һәм теләгәнчә сөт эчәләр. Аннан соң инде аларны аналарыннан аерабыз һәм көнгә 4 тапкыр гына имезәбез. Бу бер ай дәвам итә. Шуннан соң бәрәннәрне аналарыннан бөтенләй аерып, сарыкларны сава башлыйбыз.

ГАЛИМӘ СӨЛӘЙМАНОВА,

Әтнә районы, Киров исемендәге колхозның сарык караучысы.

ФРОНТ ТАЛӘП ИТКӘНЧӘ ЭШЛИК

— Син бүген фронт өчен нәрсә эшләдең? Иртәгә нәрсә эшләргә уйлыйсың?

Хәзерге чиктән тыш җаваплы вакытта безнең һәркайсыбыз алдына әнә шул сорау куелган һәм безнең бурыч (ул сорауларга тулысынча канәгатьләнерлек итеп җавап бирерлек эшләүдән, героик Кызыл Армиябезне кирәкле әйберләрнең барысы белән дә мул итеп тәэмин итүдән гыйбарәт.

Мин 8 нче ел инде колхоз фермасында эшлим: сыер савам. Безнең фермабызда эш, гомумән алганда, элек тә, сугышка кадәрге чорда да начар бармый иде. Ә сугыш башлангач, бигрәк тә 1942 нче елда, күп кенә кыенлыклар булуга карамастан, эш шактый яхшырды. Бу яхшыруны мин, табигый, үземнең эш нәтиҗәләрем белән күрсәтә алам. Мин 1941 нче елда үзем тәрбияли торган һәрбер фуражный сыердан уртача 1.377 литр сөт савып алган идем. Ә 1942 нче елда шулай ук һәрбер фуражный сыердан 1.451 литр сөт алдым. Хәкимова Рокия, Гайнетдинова Әфтап һәм башка күп кенә иптәшләрнең дә үткән елгы эш күрсәткечләре шундый ук яхшы.

Без бу уңышка сыерларны дөрес итеп тәрбияләү, азыкка нык экономия ясау нәтиҗәсендә ирештек.

Сугыш вакытында концентрат азыкка аеруча нык экономия ясалырга тиеш. Ләкин шул ук вакытта сыерларның сөт бирүләре дә кимемәскә тиеш, ә киресенчә, артырга тиеш. Без үткән көз көне бу турыда күп кенә уйлаштык, киңәштек һәм концентрат азыкны алмаштырырлык башка төр азыклардан күбрәк файдаланырга карар бирдек. Бу мәсьәләдә силос хәлиткеч урын тотты. Без үткән елны сыерлар көтүдә йөрүдән туктагач та, силос ашата башладык. Без хәзер һәрбер сыерга көненә 3 килограмм болын печәне, 3 килограмм клевер, 4 килограмм сабан ашлык саламы һәм 10 килограмм силос бирәбез. Концентрат бөтенләй бирелми. Азыкны да һәм суны да эчке тәртип кагыйдәләре буенча билгеләнгән сәгатьләрдә бирәбез. Абзарларны һәрвакыт чиста тотабыз. Сыерларны көндез бер тапкыр абзардан прогулкага чыгарабыз.

Хәзер сыерларның массовый күләмдә бозаулаулары башланды. Мин әйтә алам, 8 елдан бирле инде мин тәрбияли торган сыерларның берсе дә кысыр калганы һәм алардан туган бозауларның берсе дә үлгәне юк.

Быел да, һичшиксез, шулай булыр.

ГАЙШӘ КАДЫРОВА,

Әтнә районы, Киров исемендәге колхоз фермасының сыер саучысы.



Рәсемдә: Безнең сугышчыларның басы мы астында чигенгән вакытта дошман гаскәрләре ташлап качкан танклар. ТАСС фотохроникасы.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

16 нчы ФЕВРАЛЬДӘГЕ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

(Ахыры. Башы 1 нче биттә)

яши торган күп кенә пунктларны алдылар. Новошахтинскида безнең сугышчылар немецларның бер бронепоездын, 6 танкысын, 4 бронемашинасын, 9 орудиесен, сугыш йөкләре төялгән 35 вагонын һәм бер сугыш припаслары складын кулга төшерделәр. Икенче бер участокта безнең частьлар дошманнан 59 танк, 11 самоход орудие, 400 ләп автомашина, сугыш припаслары, снаряженниеләр һәм сугыш милекләре төялгән 177 вагон сугышып алдылар. 1500 дән артык немец солдатлары һәм офицерлары плен алынды.

* * *

Красный Сулиннан көнбатыштарак безнең частьлар һөҗүмне дәвам иттерделәр һәм халык яши торган 30 пунктны алдылар. Халык яши торган бер пункт районында Н-че часть 3 самоход пушка, 1 бронемашина 60 автомашина, 200 дән артык винтовка һәм бер сугыш припаслары склады кулга төшерелде. Сугыш кырында дошманның бик күп үле гәүдәләре калды.

* * *

Красноармейское районында безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып бардылар. Н-че часть, каты сугышлар нәтиҗәсендә, халык яши торган бер зур пунктны гитлерчылардан чистартты. 400 гә якын немец солдатлары һәм офицерлары юк ителде. 7 орудие һәм 8 миномет кулга төшерелде. Икенче бер участокта безнең сугышчылар, дошманның контратакасын кире кайтарып, бер батальонга якын гитлерчыларны кырдылар һәм немецларның 5 танкысын яндырдылар.

* * *

Харьков районында безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып баруны дәвам иттерделәр. Дошман бик каты каршылык күрсәтә. Совет частьлары куәтле ударлар ясап, дошманның оборонасын җимерделәр һәм хәзер гитлерчыларның җанлы көчләрен һәм техникасын юк итәләр. Бер участокта гына да безнең сугышчылар бик каты сугышта немецларның 43 танкысын һәм бер батальон пехотасын юк иттеләр. Икенче бер участокта совет подразделениеләре дошманның күп кенә ныгытмаларын алдылар һәм бер туктаусыз алга баралар.

Витебск партизаннарының бер группасы кинәт дошман гарнизонына һөҗүм иткән һәм 49 гитлерчыны кырып ташлаган. Калган немецлар коралларын ташлап качканнар. Икенче бер отрядның партизаннары немецларның ике хәрби эшелонын юлдан чыгарганнар. Бер паровоз, солдатлар һәм офицерлар утырган 5 вагон, автомашиналар һәм ягулык цистерналары төялгән 4 платформа җимерелгән.

* * *

Немецларның 82 нче пехота дивизиясеннән плен алынган капитан, командир адъютанты Теодор Циглер болай диде: «Немецлар командованиесенең рәсми сводкаларында, немец гаскәрләренең; оборонаның кышкы линиясен кыскарту теләге белән Кавказдан һәм Доннан план тәртибендә чигенүләре әйтелә. Ләкин бу белдерүләр безне—көнчыгыштагы офицерларны алдый алмыйлар. Үткән елны ук инде безнең дивизиянең кайбер өлкән офицерлары немец гаскәрләренең кышкы чигенүләрен дәһшәтле кисәтү дип караганнар иде. Хәзер бу офицерлар Германиянең җиңүенә булган бөтен өметләрен тәмам югалттылар. Менә өченче ай инде Германия армиясе чигенә. Хәзер инде Германиянең нинди булса да җиңүе турында сүз дә булырга мөмкин түгел. Хәзер бөтен мәсьәлә—Германия тагын күпме вакыт оборонада тора ала дигән сорауга кайтып кала».

* * *

13 нче февральдә немецларның информация бюросы түбәндәге хәбәрне тапшырды: «Германия һәм союздаш гаскәрләрнең фронтның көньяк участогында кайбер урыннарда шактый күп территория алу белән тәмам булган күп санлы контратакалары, бик сакланып кына әйткәндә; фронтта гомуми хәлнең һичшиксез яхшыруы турындагы нәтиҗәне ясарга мөмкинлек бирәләр». Шуннан бер көн үткәч, 15 нче февральдә; Гитлерның баш ставкасы; фронтның көньяк участогына немецлар армиясе ирешкән бу территория омтылышларының нәрсә икәнлеген аңлатып бирде. Гитлер ставкасының белдерүендә болай диелә: «Германия гаскәрләре, планлы операцияләр барышында, билгеләнгән план буенча төгәл хәрәкәт итеп; Ростов һәм Ворошиловград шәһәрләрен калдырдылар».

Немецлар командованиесенең бу ялган хәбәре гитлерчылар лагерында ачыктан-ачык каушау башланганлыкны бик ачык раслый. Немец гаскәрләренең Ростов һәм Ворошиловград кебек шундый бик әһәмиятле стратегия позицияләрен югалтулары, гитлерчыларның аңлатуынча, төгәл билгеләнгән план» буенча . булган имеш. Немецларның бик күп каны түгеп алынган шәһәрләрне гитлерчылар ни өчен болай кинәт кенә ташлап китәргә теләгәннәр икән дигән бик урынлы сорау туа. Билгеле, немецлар Ростовтан һәм Ворошиловградны немецлар командованиесе планы буенча китмәделәр. Немец-фашист басып алучыларны бу шәһәрләрдән Кызыл Армия бәреп чыгарды һәм аларны көнбатышка таба артларыннан куып бара. Ихтимал, иртәгә немецлар командованиесенә «немец гаскәрләре, билгеләнгән план буенча төгәл хәрәкәт итеп, Харьков шәһәрен калдырдылар» дим хәбәр итәргә туры килер.

РОСТОВНЫҢ ҺӘМ ВОРОШИЛОВГРАДНЫҢ АЛЫНУЫ ТУРЫНДА ЧИТ ИЛ МАТБУГАТЫ ҺӘМ РАДИОСЫ

АКШ

НЬЮ-ЙОРК, 15 февраль. (ТАСС). Кызыл Армиянең Ростовны һәм Ворошиловградны алуы турында хәбәр килү белән үк Америкадагы барлык радиостанцияләр бу хәбәрне бөтен илгә тараттылар. Зур радиостанцияләр бу хәбәрләрне тапшыру өчен үзләренең программаларын бүлеп тордылар.

Америка радио комментаторлары барысы да, Кызыл Армиянең Ростов-Донны алуы Германия армиясенең, һичшиксез, тар-мар ителәчәген тагын бер кат раслый, диләр. Сталинград янында 6 нчы армияне юк иткәннән соң Гитлер армиясенә үзенең әһәмияте ягыннан икенче зур удар ясалды.

Хәрби информация бюросының хәбәр итүенә караганда, Флорида штатыннан сенатор демократ Пеппег болай дигән: «Совет гаскәрләренең Ростовны алулары гадәттән тыш шатлыклы хәбәр. Нацистларның явызлык храмының нигезе тизлек белән җимерелә һәм Гитлерның бөтен бинасы аварга селкенеп тора. Әйдәгез, дошманга яңа ударлар ясыйк! Русларга дан!».

АНГЛИЯ

ЛОНДОН, 15 февраль. (ТАСС). Кызыл Армия частьларының Ростов-Донны һәм Ворошиловградны алулары турындагы хәбәр Англиядә зур тәэсир калдырды. Иртәнге газеталар бу хәбәрне бөтен беренче биткә сузылган гаять зур заголовоклар белән бирделәр. Британиянең радио компаниясе Ростовны һәм Ворошиловградны алу турындагы хәбәрне 14 нче февральдә кич белән тапшырды. Соңгы хәбәрләр тапшыру «Ростов алынган! Ростов руслар кулында!» дигән хәбәр белән берничә тапкыр өзелеп торды.

Рейтер агентлыгы үзенең махсус белдерүендә «Ростовның һәм Ворошиловградның алынуы—Кызыл Армиянең яңа тантанасы» ди.

Рейтер агентлыгының хәрби күзәтүчесе болай дип яза: «Кызыл Армия Германия армиясен тагын бер кат җиңде һәм тактик яктан үзенең анардан өстен икәнлеген күрсәтте. Донец буенда Германиянең фронт линиясе Кызыл Армиянең хәрби куәтенә каршы тора алмады. Руслар искиткеч темплар белән һөҗүм итәләр. Немец солдатларының рухы төште».

ТӨНЬЯК АФРИКАДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

ЛОНДОН, 15 февраль. (ТАСС). Рәсми рәвештә хәбәр ителүенчә, кичә Тунис фронтында патрульләр хәрәкәтләре булган.

Союзниклар авиациясе Бизерта докларын һәм башка әһәмиятле хәрби объектларны бомбага тоткан. Һава сугышларының берсендә дошманның 4 истребителе бәреп төшерелгән. Тунис белән Сицилия арасында дошманның 6 транспорт самолеты юк ителгән.

Дошман танклары, пехотасы һәм артиллериясе, пикировать итүче бомбардировщиклар ярдәме белән, Фаидадан көнбатыштарак атака ясаганнар.

Британия гаскәрләре яр буе секторында алга баруларында дәвам иткәннәр.

ЛОНДОН, 14 февраль. (ТАСС). Англиянең якын көнчыгыштагы кораллы көчләре командованиесенең белдерүендә әйтелүенчә, 13 нче февральдә, Англия гаскәрләре Бен-Гарданга таба чигенүче дошманга каршы бәрелештә булганнар.

Англия бомбардировщиклары Сицилиядә дошманның тимер юлларына зур зыян китергәннәр.

ЛОНДОН, 14 февраль. (ТАСС). Рейтер агентлыгының Англиянең 8 нче армиясендәге хәбәрчесе түбәндәге хәбәрне тапшыра:—Англиянең 7 нче бронетанк дивизиясенең алгы частьлары Бен-Гарданнан төньяк-көнчыгыштарак алган позицияләренә урнаштылар. Немецлар үзләренең терәк пунктларының берсендә дә көчле каршылык күрсәтмиләр. Алар, англичаннарның басымы астында, Бен-Гарданнан чигенәләр. Соңгы сугышлар вакытында немецларның һавада бик йомшак булулары күренде. Озакка сузылган чигенү вакытында булган югалтуларын Германия авиациясе әле кайтара алмаган, күрәсең.

АНГЛИЯ АВИАЦИЯСЕНЕҢ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

ЛОНДОН, 15 февраль. (ТАСС). Англиянең авиация министрлыгының белдерүендә әйтелүенчә, 15 нче февральдә көндез «Бостон» һәм «Вентура» бомбардировщиклары Франциянең Булонь һәм Сен-Мало докларын, андагы пароходларны һәм Голландиянең Эймейдендагы металлургия заводын бомбага тотканнар. Бомбардировщиклар барысы да үз базаларына кайтканнар.

Англия бомбардировщиклары 14 нче февральгә каршы төндә Лорианга ике тапкыр һөҗүм иткәннәр. Операцияләр өчен һава яхшы булган һәм атакалар икесе дә бик көчле булганнар. Беренче алынган хәбәрләргә караганда, гадәттән тыш зур җимерелүләр булган. Шулай ук Көнбатыш Германиядәге күп кенә объектларга да бомбалар ташланган.

ЛОНДОН, 15 февраль. (ТАСС). 15 нче февральгә каршы төндә Англия самолетлары зур операцияләр үткәргәннәр. Башлыча Германиядә Кельн шәһәре һәм Италиядә Милан шәһәре бомбага тотылган. Кельнгә бомбалар 30 минут буена ташланып торган. Дошманның зенит артиллериясе гадәттәгегә караганда азрак активлык күрсәткән, ләкин һавада дошманның бик күп истребительләре күренгән. Шәһәргә күп санда фугаслы һәм яндыргыч бомбалар ташланган.

Италиянең зурлык ягыннан икенче урында тора торган Милан шәһәрендә зур янгыннар чыккан. Милан—Италиянең төп транспорт үзәкләреннән берсе. Анда бер миллионнан артык кеше тора. Ләкин шәһәрдә һава һөҗүменнән саклану мәсьәләсе качар хәлдә булган. Хәтта истребительләр дә булмаган.

Бу операцияләрдән Англиянең 11 самолеты үз базаларына кайтмаган.

Грециядә гитлерчыларның канлы җинаятьләре

ЛОНДОН, 15 февраль. (ТАСС). «Франс» газетасының язуына караганда, Греция патриотларының Греция белән Югославия арасындагы тимер юл күперен шартлатып, ике ил арасында хәбәрләшүне өзүләре аркасында илдә террор тагын да көчәйгән. Күптән түгел Лариса шәһәрендә Греция полковнигы Паракириазис атып үтерелгән. Аны Грециядәге бер күперне шартлатуны оештыруда гаепләгәннәр. Немецлар Греция партизаннарының командиры полковник Спайсны исән килеш тотып китерүчегә яки үтерүчегә 100 миллион драхма бүләк вәгъдә иткәннәр. Генерал Оконайос, генерал Манетас һәм адмирал Колналекссис кулга алынганнар.

ЖЕНЕВА, 15 февраль. (ТАСС). Монда алынган хәбәрләргә караганда, күптән түгел Греция партизаннары күчәр державаларының сугыш материаллары һәм гаскәрләр төялгән 2 поездын юлдан чыгарганнар. Шул ачудан 34 кеше җәзалап үтерелгән һәм 2 авыл яндырылган.

АМЕРИКА АВИАЦИЯСЕ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

НЬЮ-ЙОРК, 15 февраль. (ТАСС). Ассошиэйтед Пресс агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Америка авиациясе 10 нчы февральдә японнарның 3 эсминецын батырган һәм кимендә 4 эсминецны зарарлаган. 2 эсминецка, алар япон гаскәрләрен Гвадалканар атавыннан күчерергә булышлык иткән чакта атака ясалган.

Новая Георгия атавы районында бер юлы 20 эсминецка һөҗүм ясалган. Һава сугышларында японнарның 17 истребителе бәреп төшерелгән.

БЕЛДЕРҮ

Бүген, 19 сәгатьтә ВКП(б) Өлкә Комитетының һәм шәһәр комитетының Партия мәгариф Йортында (Бауман урамы, 62 нче йорт) партия активы өчен «Партия төзелеше турында Ленин һәм Сталин» дигән темага лекция үткәрелә. Лектор—ВКП(б) шәһәр комитеты секретаре иптәш Н. Г. Грекова. Билетларны ВКП(б) ның шәһәр райкомнарыннан алырга.

ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитеты һәм Татарстан АССР Совнаркомы ВКП(б) Арча райкомының беренче секретаре, Бөтенсоюз Коммунистлар (большевиклар) Партиясе члены иптәш Исхак Кәрим улы Кәримовның озак һәм каты авырудан соң 1943 нче елның 16 нчы февралендә үлгәнлеген кайгы белән белдерәләр һәм семьясының кайгысын уртаклашалар.

ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитеты.

Татарстан АССР Совнаркомы.

Җаваплы редактор И. ҮЗБӘКОВ.

Редакциянең телефон номерлары: җаваплы редактор, редактор урынбасары— АТС 76—29, секретарь, промышленность - транспорт һәм авыл хуҗалыгы бүлеге— АТС 79—29. типография 36—60.

ПФ1031 «КРАСНАЯ ТАТАРИЯ» һәм «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН» издательствосының АЛЕКСАНДРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТИПОГРАФ ИЯСЕ № Заказ 236